КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.09.2024 Казан шәһәре № 482-П

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан «I Биләр торак җирлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның махсус режимын раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 12 нче июлендәге 565 нче номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Расларга:

әлеге боерыкка караган 1 нче кушмта нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан «I Биләр торак җирлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

әлеге боерыкка караган 2 нче кушмта нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан «I Биләр торак җирлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектыннан файдалануның махсус режимын;

2. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
30 нчы сентябрендәге 481-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан «I Биләр торак җирлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектыннан
**файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы 2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон), 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын, урманнардан файдалану һәм башка төрле эшләр, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин иткән очракта башкарылырга мөмкин.

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан су объектыннан яисә аның өлешеннән файдалануның махсус режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә уздыруын тәэмин итү шарты белән Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Разрешается:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә, һәйкәлне өйрәнү эшләрен, археологик предметларны эзләү һәм алып китү максатын күздә тоткан эшләрне башкару;

ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару, саклап калу, алардан файдалану өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән эшләрне гамәлгә ашыру шарты белән, мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында йә уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында мәҗбүри бүлекләрнең мәдәни мирас объектларын популярлаштыруны һәм саклауны;

гражданнарның археологик мирас объектына керүләрен законнар нигезендә оештыру;

**2. Тыела:**

ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30

статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен, мәдәни мирас объектларын саклап калу, мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында, йә уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгәннәрне гамәлгә ашырмыйча, археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү.